# Новости из «Светофорика»
# «Үткүзкәй» яңалыклары



Выпуск № 3
19 марта 2026

**Хөрмәтле әниләр, апалар һәм кызлар!**
**Котлыйбыз сезне Халыкара хатын – кызлар көне – 8 март бәйрәме белән! Сезгә чын күңелебездән телибез исәнлек, саулык, тынычлык, иминлек, гаилә татулыгы, бәхет, зур унышлар һәм шатлыклар! Яз бәйрәме сезгә гел шатлыклар, куанычлар гына алып килсен. Балаларыгыз сезне гел шатландырсыннар.**

## 8 нче март - Әниләр бәйрәме

(С.Сөләйманова)



**Кояш көлә, мин елмаям,**
**8 нче Март бүген.**
**Бүген әниләр бәйрәме,**
**Шуңа күңелем шат минем.**
**Кайсын юам, кайсын җыям,**
**Чиста булсын, ак булсын.**
**Әниләрнең күңеледәй**
**Бөтен нәрсә пакъ булсын.**
**Бәйрәм бүген, бәйрәм! – диеп,**
**Бар дөнья көлеп торсын.**
**Әни бәйрәме икәнен**
**Әти дә белеп торсын,**
**Әти дә көлеп торсын!**



## Нәүрүз килә

**Нәүрүз килә**
**Җиргә, илгә.**
**Нәүрүз, Нәүрүз, Нәүрүз!**
**Шатлык белән, бәхет белән!**
**Түрдән уз! Түрдән уз!**



Нәүрүз – кышны озату, язны каршылау бәйрәме. Нәүрүз – ул язгы бәйрәм. Ул тынычлыкка, матурлыкка өндәүче бәйрәм. Һәр елны бакчабызда татар халкының иң яраткан Нәүрүз бәйрәме уткэрелә. Балалар бу бәйрәмне бик көтеп алалар. Бәйрәмебезгә яраткан геройларыбыз Нәүрүзбикә, Шүрәле, Убырлы кунакка килде. Балалар бәйрәмдә узләренен яраткан җырларын җырладылар, шигырьләрен сөйләделәр. Төрле биюләр, татар халкының уеннары: “Түбәтәй”, “Капкалы” уткәрелде.

## Весенние утренники!

В период с 2 по 5 марта 2026 года во всех дошкольных группах детского сада прошли весенние утренники посвященные «Международному женскому дню 8 Марта!»

Новости из «Светофорика»
Выпускается с 2026 года
Над выпуском работали:
воспитатель по обучению детей татарскому языку
Мирсаяпова Г.Х.,
старшийевоспитатели: Ефимова Е.А., Садриева Л.И.

Адрес редакции: МБДОУ № 53«Светофорик»
Электронная почта: dou53.svetoforik@yandex.ru